## Пресс-релиз

**IT-чемпионы среди татарстанских школьников получат 270 смартфонов**

*В Татарстане стартовал конкурс среди школьников «IT-чемпион». Главная задача юных участников конкурса – приобщить родителей и взрослых к активному пользованию электронными сервисами на Портале госуслуг РТ и заработать при этом максимальное количество призовых баллов. Конкурс проводится Министерством информатизации и связи РТ совместно с Министерством образования и науки РТ с целью развития цифровых навыков школьников и повышения компьютерной грамотности населения.*

Конкурс пройдет в два этапа: с 18 сентября по 30 ноября 2018 года и с 1 февраля по 30 апреля 2019 года. По итогам каждого этапа конкурса в каждом муниципальном районе и городском округе будут определены по 3 победителя, которым в качестве приза будут вручены смартфоны. Отдельная номинация организована для самых активных классных руководителей, чей класс наберет наибольшее среднее количество баллов.

Чтобы приступить к соревнованию, школьнику необходимо помочь родителям или другим взрослым зайти на Портал uslugi.tatarstan.ru и сохранить в личном кабинете логин школьника с сайта edu.tatar.ru (Электронное образование РТ). Привязка необходима, чтобы школьнику автоматически начислялись баллы, когда обученные им взрослые пользователи будут использовать Портал – подавать электронные заявления, оплачивать услуги и даже вводить показания счетчиков. Важно отметить, что чем больше взрослых пользователей привяжут к своему личному кабинету на Портале логин школьника, тем больше у этого ребенка шансов набрать наибольшее количество баллов.

Как отмечает заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр информатизации и связи **Роман Шайхутдинов**, сегодня большинство услуг доступны в электронном виде и это значительно упрощает жизнь татарстанцев - не нужно проводить время в очередях, ходить по инстанциям с бумажными заявлениями. Однако еще не все граждане познали удобство получения услуг в режиме «онлайн» – в этом им как раз и поможет молодое поколение.

«Уже многие взрослые благодаря нашим ребятам изучили возможности Портала и широко используют их в повседневной жизни при оплате коммунальных услуг, записи на прием к врачу и получении различных официальных справок, – отметил заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр образования и науки **Рафис Бурганов.** - Я уверен, что интерес к участию в конкурсе сохранится и, благодаря IT-знаниями и навыкам татарстанских школьников, еще большее число жителей республики приобщится к получению государственных и муниципальных услуг через Интернет», - подчеркнул он.

*Для справки:*

*Портал государственных и муниципальных услуг Республики Татарстан – справочно-информационный интернет-портал, с помощью которого можно получить государственные, муниципальные и социально значимые услуги в электронном виде. По состоянию на 2018 год на Портале зарегистрированы более 2,2 млн человек.*

*На Портале госуслуг Республики Татарстан реализована возможность:*

- *направления электронных запросов;*
- *подачи электронных заявлений на получение услуг;*
- *online-оплаты услуг любыми банковскими картами;*
- *записи на прием к врачу или специалистам ведомств.*

*В общей сложности на Портале представлены около 250 различных услуг и сервисов. 20 наиболее востребованных из них реализованы в мобильном приложении «Услуги РТ», доступном для скачивания в AppStore и Play Market.*

***Контакты для связи:***


| | |
|---|---|
| ***Анна Яковлева,***<br>*пресс-служба Министерства информатизации и связи РТ*<br>*8(843)264-73-34* | ***Алсу Мухаметова,***<br>*пресс-служба Министерства образования и науки РТ*<br>*8(843)294-95-29* |

**Пресс-релиз**

**Татарстан укучылары арасындагы IT-чемпионнар 270 смартфон алачак**

*Татарстанда укучылар арасында «IT-чемпион» бәйгесе башланды. Бәйгенең яшь катнашучыларының төп бурычы – ата-аналарны һәм өлкән яшьтәгеләрне ТР Дәүләт хезмәтләре порталындагы электрон сервисларны даими куллануга күнектерү һәм шуның белән мөмкин кадәр күбрәк баллар җыю. Бәйге укучыларның цифрлы күнекмәләрен үстерү һәм халыкның компьютер куллanудагы грамоталылыгын арттыру максатыннан ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә үткәрелә.*

Бәйге ике этапта узачак: 2018 елның 18нче сентябреннән 30нчы ноябренә кадәр һәм 2019 елның 1нче февраленнән 30нчы апреленә кадәр. Һәр этапның нәтиҗәләре буенча һәр муниципаль районда һәм шәһәр округында 3 җиңүче билгеләнәчәк һәм аларга смартфон бүләк ителәчәк. Укучылары иң күп уртача балл җыйган иң актив сыйныф җитәкчеләре өчен аерым номинация булачак.

Бәйгедә катнашу өчен укучыга әти-әнисенә яисә башка өлкән яшьтәгеләргә uslugi.tatarstan.ru Порталына керергә булышырга һәм укучының edu.tatar.ru сайтындагы (ТР Электрон белем бирү) логинын шәхси кабинетта саклап куярга кирәк. Өлкәннәр Порталны кулланган саен (электрон рәвештә гариза бирсәләр, хезмәт күрсәтү өчен түләсәләр яисә счетчик күрсәтмәләрен җибәрсәләр) укучыга баллар автоматик рәвештә өстәлеп барачак. Кайсы укучының логинын күбрәк өлкән кулланучы Порталда үзенең шәхси кабинетына беркетсә, шуның күбрәк балл җыюга мөмкинлеге артачак.

ТР Премьер-министры урынбасары –ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов билгеләп үткәнчә, бүгенге көндә электрон рәвештәге күп кенә хезмәт күрсәтү төрләрен һәр кеше куллана ала һәм бу татарстанлыларның тормышын күпкә җиңеләйтә, чөнки гариза тотып төрле идарә оешмаларына барып, чират торып, вакыт үткәрергә кирәк түгел. Шулай да әлегә барлык гражданнар да «онлайн» режимында хезмәт күрсәтүнең уңайлылыгын аңлап җиткерми. Бу өлкәдә аларга нәкъ менә яшьләр ярдәм күрсәтә ала.

«Инде күп кенә өлкән яшьтәгеләр безнең укучылар ярдәме белән Порталның мөмкинлекләрен өйрәнделәр һәм көндәлек тормышта киң кулланалар, - дип билгеләп үтте ТР Премьер-министры урынбасары – ТР мәгариф һәм фән

министры Рәфис Борһанов. – Мин ышанам, укучыларның бу бәйгедә катнашырга кызыксынулары артыр һәм Татарстан укучыларының IT-белемнәре һәм күнекмәләре ярдәмендә республикабызда яшәүчеләрнең тагын да күпчелеге Интернет челтәре аша дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушылып китәр, - дип ассызыклап әйтте.

*Белешмә өчен:*

*Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы – белешмәле-мәгълүмати интернет-портал. Аның ярдәмендә дәүләт һәм муниципаль хезмәте, социаль яктан мөһим булган хезмәт күрсәтүләрне электрон рәвештә алырга була. 2018 елга Порталда 2,2 млн кеше теркәлгән.*

*ТР Дәүләт хезмәтләре порталында түбәндәге мөмкинлекләрдән файдаланырга була:*

- *электрон рәвештә мөрәҗәгать җибәрү;*
- *хезмәт күрсәтүгә электрон рәвештә гаризалар җибәрү;*
- *төрле банк карталары белән хезмәт күрсәткән өчен online-түләү;*
- *табибка яисә дәүләт идарәсе тармаклары хезмәткәрләренә кабул итүгә язылу.*

*Гомумән алганда, Порталда 250гә якын хезмәт күрсәтү төре тәкъдим ителгән. Шуларның иң киң кулланылган 20се AppStore и Play Marketка кучереп яздырырга мөмкин булган «ТР хезмәт күрсәтүләре» («Услуги РТ») мобиль кушымтасында тормышка ашырыла.*

***Элемтә өчен мәгълүмат:***


| | |
|---|---|
| ***Анна Яковлева,***<br>*ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы матбугат хезмәте*<br>*8(843)264-73-34* | ***Алсу Мухаметова,***<br>*ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы матбугат хезмәте*<br>*8(843)294-95-29* |